| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«17» март 2023г. № 51

Муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару турында, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү турында

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча аерым чаралар турында» 2022 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2022 елның 9 августындагы 775 номерлы «Татарстан Республикасы Дәүләт милке һәм (яки) муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару турында, Татарстан Республикасы Дәүләт оешмасы, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура төзүче Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү турында» карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

- Муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләү яисә юкка чыгару турында, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибе, 1 номерлы кушымта нигезендә;

- Балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибе, 2 номерлы кушымта нигезендә;

- Муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләү яисә юкка чыгару турында, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү буенча комиссия төзү тәртибе, 3 номерлы кушымта нигезендә;

- Алар нигезендә балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару, оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзүнең нәтиҗәләре бәяләнә торган критерийлар әһәмияте, 4 номерлы кушымта нигезендә;

- Муниципаль мәгариф учреждениеләрен үзгәртеп оештыру (бетерү) нәтиҗәләрен эксперт бәяләвен үткәрү буенча эксперт комиссиясе составы, 5 номерлы кушымта нигезендә;

- Муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару турында, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия составы, 6 номерлы кушымта нигезендә.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 1 августындагы 623 номерлы «Балалар өчен социаль инфраструктура объектлары булып торучы Теләче муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре тарафыннан аренда шартнамәләре төзү нәтиҗәләрен эксперт тарафыннан бәяләү уздыру тәртибен раслау турында» карары;

- Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 31 августындагы 416 номерлы «Муниципаль мәгариф учреждениеләрен үзгәртеп оештыру (бетерү) нәтиҗәләрен эксперт бәяләүсен уздыру буенча эксперт комиссиясе төзү турында» карары;

- Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 7 маендагы 256 номерлы «Муниципаль мәгариф учреждениеләрен үзгәртеп оештыру (бетерү) нәтиҗәләрен эксперт бәяләүне үткәрү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» карары.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

1 номерлы кушымта
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«17» 03 2023 № 51
карары белән расланды

Муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләү яисә юкка чыгару турында, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 5 өлеше, «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча аерым чаралар турында» 2022 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2022 елның 9 августындагы 775 номерлы «Татарстан Республикасы Дәүләт милке һәм (яки) муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару турында, Татарстан Республикасы Дәүләт оешмасы, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура төзүче Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү турында» карары нигезендә эшләнелгән һәм муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару турында, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен, шулай ук эксперт бәяләмәсе критерийларын бәяләү процедурасын регламентлаштыра.

2. Әлеге Тәртиптә аны куллану максатлары өчен түбәндәге терминнар кулланыла:

*Оешма* - балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма.

*Вәкаләтле орган* - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының оешма гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы.

*Эксперт бәяләве* - муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләү яки ябу турында, аренда шартнамәсен оештыру турында, беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү.

*Балалар өчен социаль инфраструктура объекты* - муниципаль милек булган балаларны тормыш белән тәэмин итү өчен кирәкле бина, төзелеш, корылма.

*Социаль инфраструктура объектын балалар өчен куллану* - балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү.

*Комиссия* - балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару турында, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү буенча комиссия.

3. Эксперт бәяләмәсен оешманың вәкаләтле органга мөрәҗәгате нигезендә яисә вәкаләтле орган инициативасы белән гамәлгә ашыра.

4. Социаль инфраструктура объектыннан балалар өчен файдалану турында карар кабул итү өчен вәкаләтле орган комиссиягә үз инициативасы белән яисә оешма мөрәҗәгате нигезендә эксперт бәяләвен уздыру турында язма гариза җибәрә, ул түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) балалар өчен социаль инфраструктура объектының тулы исеме, аның урнашу урыны адресы, гариза биргән көнгә торышы буенча балалар өчен социаль инфраструктура объектын билгеләү һәм фактта эксплуатацияләүгә күрсәтү (шул исәптән оператив идарә хокукында беркетү турындагы белешмәләр, аренда шартнамәсе буенча вакытлыча файдалануга тапшыру, түләүсез файдалану һ.б.);

б) оешмага беркетелгән балалар өчен социаль инфраструктура объектыннан файдалану турында карар кабул итүнең кирәклеген һәм (яисә) максатчанлыгын нигезләү;

в) балаларның тормыш эшчәнлеген, мәгарифен, үсешен, ялын һәм аларны савыктыруны тиешенчә тәэмин итү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, балаларда авыруларны профилактикалау, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү мөмкинлеген оешмага беркетелгән балалар өчен тиешле социаль инфраструктура объектыннан файдаланганнан соң нигезләү;

г) балигъ булмаган балаларның тормыш эшчәнлеген, белем алуын, үсешен, ялын һәм сәламәтләнүен тәэмин итүгә, аларга медицина ярдәме күрсәтүгә, балаларда авыруларны профилактикалауга, аларны социаль яклауга һәм социаль хезмәт күрсәтүгә законнарда билгеләнгән хокукларын үтәү өчен мөмкин булган һәм (яки) күздә тотылган чаралар турында тәкъдимнәр.

5. Әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән гаризага түбәндәгеләр кушымта итеп бирелә:

а) балалар өчен социаль инфраструктура объектына хокук билгели торган документларның күчермәләре;

б) оператив идарә итү хокукында балалар өчен социаль инфраструктура объектын беркетүне раслый торган документлар күчермәләре, аренда шартнамәсе буенча вакытлыча файдалануга тапшыру, түләүсез файдалану яисә башка (булган очракта);

в) балалар өчен социаль инфраструктура объектының техник торышы турында белешмәләр булган документларның, оешманың матди-техник базасының торышы, шул исәптән оператив идарә хокукында оешмага беркетелгән мөлкәт турында (булган очракта);

г) социаль инфраструктура объектыннан балалар өчен файдалану турында тиешле карар кабул итүнең зарурлыгын һәм максатчанлыгын раслый торган документлар (булган очракта);

д) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларның күчермәләре (булган очракта).

Документлар әлеге Тәртип таләпләрен исәпкә алып, вәкаләтле органга яисә вәкаләтле орган тарафыннан кәгазь чыганакларда комиссиягә тапшырыла.

Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, аларга буйсынган оешмалар карамагында булган кирәкле документларны, әгәр күрсәтелгән документлар оешма тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тәкъдим ителмәсә, сорый.

6. Әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән гариза һәм документлар оешманың вәкаләтле органы яки комиссиянең вәкаләтле органына кире кайту сәбәпләрен күрсәтеп, кергән көннән алып өч эш көне эчендә кайтарылырга тиеш. Әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган гариза һәм документлар оешмадан комиссиягә кергән көннән соң вәкаләтле орган тарафыннан өч эш көне эчендә җибәрелә.

Гаризаны һәм документларны кире кайтару сәбәбе булган хокук бозуларны бетергәннән соң, оешма кабат вәкаләтле органга яисә вәкаләтле орган эксперт бәяләвен уздыру турындагы гариза белән комиссиягә кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

7. Эксперт бәяләве түбәндәге критерийлар нигезендә уздырыла:

а) реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләнешен үзгәртү яки бетерү, шулай ук аны арендага бирү, түләүсез файдалану өчен тәкъдим ителгән социаль инфраструктура объектын кулланып бирелә торган балаларга тормыш эшчәнлеген тәэмин итү, белем бирү, үсеш, ял итү һәм сәламәтләндерү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, балаларда авыруларны профилактикалау, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү максатларында социаль хезмәтләр күрсәтүне дәвам итү;

б) реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләнешен үзгәртү яки бетерү, шулай ук аны арендага бирү, түләүсез файдалану өчен тәкъдим ителгән социаль инфраструктура объектын кулланып бирелә торган балаларга тормыш эшчәнлеген тәэмин итү, белем бирү, үсеш, ял итү һәм сәламәтләндерү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, балаларда авыруларны профилактикалау, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү максатларында хезмәтләр күрсәтү;

в) социаль инфраструктура объектыннан социаль инфраструктура объектыннан файдалану турында карар үтәү нәтиҗәсендә балалар өчен норматив таләпләргә туры килүен тәэмин итү.

8. Алар нигезендә балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару, оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзүнең нәтиҗәләре бәяләнә торган критерийлар әһәмияте вәкаләтле орган тарафыннан раслана.

2 номерлы кушымта
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«17» 03 2023 № 51
карары белән расланган

Балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 5 өлеше, «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча аерым чаралар турында» 2022 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2022 елның 9 августындагы 775 номерлы «Татарстан Республикасы Дәүләт милке һәм (яки) муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару турында, Татарстан Республикасы Дәүләт оешмасы, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура төзүче Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү турында» карары нигезендә эшләнелгән муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару, шулай ук эксперт бәяләмәсе критерийларын бәяләү процедурасын регламентлаштыра

2. Әлеге Тәртиптә аны куллану максатлары өчен түбәндәге терминнар кулланыла:

*Оешма* - балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма.

*Вәкаләтле орган* - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының оешма гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы.

*Эксперт бәяләве* - оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү.

*Комиссия* - балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару турында, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү, шулай ук балалар өчен социаль

инфраструктура төзүче муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү буенча комиссия.

3. Эксперт бәяләмәсен оешманың вәкаләтле органга мөрәҗәгате нигезендә яисә вәкаләтле орган инициативасы белән гамәлгә ашыра.

4. Оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү өчен вәкаләтле орган үз инициативасы белән яисә оешма мөрәҗәгате нигезендә эксперт бәяләмәсен уздыру турында язма гариза җибәрә, ул түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) шундый ук үзгәртеп оештырыла торган яисә бетерелә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмаларның тиешле территориясендә урнашкан белешмәләр, шул исәптән балаларны үзгәртеп оештырыла торган яисә бетерелә торган оешма итеп башка оешмаларга күчерү мөмкинлеге турында (булган очракта);

б) үзгәртеп оештырыла торган оешма хезмәткәрләренең штат санын кыскарту яисә арттыру, оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү нәтиҗәсендә азат ителә торган хезмәткәрләрне эшкә урнаштыру мөмкинлеге турында белешмәләр;

в) оешманың матди-техник базасының торышы турында, шул исәптән оператив идарә итү хокукында оешмага беркетелгән (беркетелгән) мөлкәт турында, шулай ук билгеләнгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә мөлкәттән файдалану перспективалары турында белешмәләр;

г) оешманы үзгәртеп оештыру яисә бетерү турында карар кабул итүнең кирәклеген һәм (яисә) максатчанлыгын нигезләү;

д) оешманы үзгәртеп оештыру яисә бетерү чараларын финанслауга ассигнованиеләр күләмен күрсәтеп, тәкъдим ителә торган үзгәрешләрнең финанс-икътисадый нигезләнүе.

5. Әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән гаризага түбәндәгеләр кушымта итеп бирелә:

а) оешманың хокук билгели торган документларының күчермәләре;

б) оешманың техник торышы, матди-техник базасының торышы турында белешмәләр булган документларның, шул исәптән оператив идарә хокукында оешмага беркетелгән мөлкәт турында (булган очракта) документларның күчермәләре;

в) оешманы үзгәртеп оештыру яисә бетерү турында тиешле карар кабул итүнең кирәклеген һәм максатка ярашлылыгын раслый торган документлар (булган очракта);

г) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларның күчермәләре (булган очракта).

Документлар, әлеге Тәртип таләпләрен исәпкә алып, вәкаләтле органга яисә вәкаләтле орган тарафыннан комиссиягә кәгазь чыганакларда бирелә.

Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, аларга буйсынган оешмалар карамагында булган кирәкле документларны, әгәр күрсәтелгән документлар оешма тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тәкъдим ителмәсә, сорый.

6. Әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән гариза һәм документлар оешманың вәкаләтле органы яки комиссиянең вәкаләтле органына кире кайту сәбәпләрен күрсәтеп, кергән көннән алып өч эш көне эчендә кайтарылырга тиеш. Әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында

билгеләнгән таләпләргә туры килә торган гариза һәм документлар оешмадан комиссиягә кергән көннән соң вәкаләтле орган тарафыннан өч эш көне эчендә җибәрелә.

Гаризаны һәм документларны кире кайтару сәбәбе булган хокук бозуларны бетергәннән соң, оешма кабат вәкаләтле органга яисә вәкаләтле орган эксперт бәяләвен уздыру турындагы гариза белән комиссиягә кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

7. Эксперт бәяләве түбәндәге критерийлар нигезендә уздырыла:

а) билгеләнешен үзгәртү яки бетерүгә тәкъдим ителгән социаль инфраструктура объектын кулланып бирелә торган балаларга тормыш эшчәнлеген тәэмин итү, белем бирү, үсеш, ял итү һәм сәламәтләндерү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, балаларда авыруларны профилактикалау, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү максатларында социаль хезмәтләр күрсәтүне дәвам итү;

б) билгеләнешен үзгәртү яки бетерүгә тәкъдим ителгән социаль инфраструктура объектын кулланып бирелә торган балаларга тормыш эшчәнлеген тәэмин итү, белем бирү, үсеш, ял итү һәм сәламәтләндерү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, балаларда авыруларны профилактикалау, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү максатларында хезмәтләр күрсәтү;

в) үзгәртеп коруга яисә бетерүгә тәкъдим ителә торган оешма тарафыннан гына гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруны дәвам итүне тәэмин итү.

8. Оешманы үзгәртеп кору яисә бетерү нәтиҗәләрен бәяләүче критерийларның әһәмиятләре вәкаләтле орган тарафыннан раслана.

3 номерлы кушымта
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«17» 03 2023 № 51
карары белән расланды

Муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләү яисә юкка чыгару турында, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү буенча комиссия төзү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 5 өлеше, «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча аерым чаралар турында» 2022 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2022 елның 9 августындагы 775 номерлы «Татарстан Республикасы Дәүләт милке һәм (яки) муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару турында, Татарстан Республикасы Дәүләт оешмасы, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура төзүче Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү турында» карары нигезендә эшләнелгән һәм муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару турында, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен, шулай ук бәяләмә әзерләү процедурасын регламентлаштыра.

2. Әлеге Тәртиптә аны куллану максатлары өчен түбәндәге терминнар кулланыла:

*Оешма* - балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма.

*Вәкаләтле орган* - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының оешма гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы

җирле үзидарә органы.

*Эксперт бәяләве* - муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләү яки ябу турында, аренда шартнамәсен оештыру турында, беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү.

*Балалар өчен социаль инфраструктура объекты* - муниципаль милек булган балаларны тормыш белән тәэмин итү өчен кирәкле бина, төзелеш, корылма.

*Социаль инфраструктура объектын балалар өчен куллану* - балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү.

*Комиссия* - балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару турында, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү буенча комиссия.

3. Комиссия составы вәкаләтле орган акты белән раслана. Комиссия, рәисне дә кертеп, кимендә биш кешедән тора. Комиссия составына вәкаләтле орган хезмәткәрләре керә. Комиссия составына шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, вәкаләтле орган каршындагы иҗтимагый совет, башка оешмалар, экспертлар керергә мөмкин, шул ук вакытта вәкаләтле орган хезмәткәрләре комиссиянең гомуми составыннан кимендә өчтән берен тәшкил итәргә тиеш.

Комиссия эше утырышларда башкарыла, комиссия утырышлары кирәк саен уздырыла.

4. Комиссия эшчәнлеге җитәкчелеген аның рәисе башкара (ул булмаганда - рәис урынбасары).

5. Комиссия рәисе комиссия эшчәнлеген планлаштыра, комиссия утырышларын алып бара, комиссиянең кабул ителгән карарларының үтәлешен тәэмин итә һәм контрольдә тота, рәискә йөкләнгән вазыйфаларны һәм бурычларны үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен шәхсән җаваплы була.

6. Комиссия утырышында комиссия гомуми составының кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы була.

7. Комиссия карарында түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) үзгәртеп оештыруга яисә бетерүгә тәкъдим ителә торган оешманың исеме (оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү нәтиҗәләрен бәяләгән очракта);

б) балалар өчен социаль инфраструктура объектының тулы исеме, аның урнашу урыны адресы, гариза биргән көнгә балалар өчен социаль инфраструктура объектын билгеләү һәм фактта эксплуатацияләүгә күрсәтү, шул исәптән оператив идарә хокукында беркетү турында белешмәләр, аренда шартнамәсе буенча вакытлыча файдалануга тапшыру, түләүсез файдалану һ.б.

(социаль инфраструктура объектыннан балалар өчен файдалану нәтиҗәләрен бәяләгән очракта);

в) балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләп кую яисә бетерү турында, аренда шартнамәсен оештыру турында, беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында, комиссия утырышына чыгарылган оешмаларны үзгәртеп оештыру яисә бетерү турында вәкаләтле органның тәкъдиме;

г) балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләнешен яисә бетерү, аренда Шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе, оешмаларны үзгәртеп оештыру яисә бетерү Шартнамәсе төзү нәтиҗәләре бәяләнә торган вәкаләтле орган тарафыннан раслана торган барлык критерийларның әһәмияте;

д) комиссия карары.

8. Социаль инфраструктура объектыннан балалар өчен файдалану нәтиҗәләрен бәяләү үткәрелгәндә, комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

а) соратуларны дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, учреждениеләргә һәм оешмаларга җибәрергә;

б) законнар нигезендә дәлилләнгән, документаль һәм норматив нигезләнгән карар кабул итү өчен кирәкле башка гамәлләрне гамәлгә ашырырга.

9. Комиссия эксперт бәяләвен уздыру турында язма гаризаны һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларны карый, белгечләрнең нәтиҗәләрен гомумиләштерә, документларны карау нәтиҗәләре буенча алар кергән көннән алып 30 көн эчендә карар кабул итә, карар бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә (алга таба - бәяләмә). Комиссия бәяләмәсе комиссия утырышында катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышларның саны бертигез булганда, утырышта рәислек итүче тавыш хәлиткеч булып тора (ул булмаганда - рәис урынбасары).

Комиссия балалар өчен социаль инфраструктура объектыннан файдалану турында, уздырылган анализ нәтиҗәләре буенча балалар өчен социаль инфраструктура объектыннан файдалану нәтиҗәләре, оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында вәкаләтле орган тарафыннан раслана торган критерийлар күрсәткечләренең берсенә генә булса да ирешелмәгән очракта, оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында тискәре бәяләмә бирә.

Комиссия, үткәрелгән анализ нәтиҗәләре буенча вәкаләтле орган билгеләгән критерийларның барлык күрсәткечләренә ирешелгән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән критерийлар күрсәткечләреннән тыш, социаль инфраструктура объектыннан балалар өчен файдалану турында, оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү мөмкинлеге хакында уңай нәтиҗә бирә.

10. Бәяләмә комиссиянең утырышта катнашкан барлык әгъзалары тарафыннан кимендә ике нөсхәдә имзалана һәм аның рәисе тарафыннан раслана. Комиссия әгъзаларының аерым фикерләре бәяләмәгә кушып бирелә.

11. Бәяләмә имзаланганнан соң биш көн эчендә комиссия тарафыннан вәкаләтле органга тапшырыла. Бер нөсхә оешманың вәкаләтле органы тарафыннан тапшырыла.

4 номерлы кушымта
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«17» 03 2023 № 51
карары белән расланды

Алар нигезендә балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару, оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзүнең нәтиҗәләре бәяләнә торган критерийлар әһәмияте

| Критерийның атамасы | Критерийның әһәмияте |
|---|---|
| Үзгәртеп оештыру яки бетерү өчен тәкъдим ителә торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү максатларында балаларга социаль хезмәт күрсәтүне дәвам итү | Тәэмин ителгән / тәэмин ителмәгән |
| Балаларга социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү максатларында, тиешле карар кабул ителгәнчегә кадәр, оешма тарафыннан тәкъдим ителә торган социаль хезмәт күрсәтүләрнең кимендә күләме күләмендә социаль хезмәтләр күрсәтү | Тәэмин ителгән / тәэмин ителмәгән |
| Үзгәртеп коруга яисә бетерүгә тәкъдим ителә торган оешма тарафыннан гына гамәлгә ашырылган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруны дәвам итүне тәэмин итү | Тәэмин ителгән / тәэмин ителмәгән |

5 номерлы кушымта
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«17» 03 2023 № 51
карары белән расланды

Муниципаль мәгариф учреждениеләрен үзгәртеп оештыру (бетерү) нәтиҗәләрен эксперт бәяләвен үткәрү буенча эксперт комиссиясе составы

Комиссия рәисе:

Гыйниятуллин Д.С. - Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары

Комиссия рәисе урынбасары:

Карпова Н.В. - МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» башлыгы.

Комиссия секретаре:

Шигаева С.И. - МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» нең әйдәп баручы белгече.

Комиссия әгъзалары:

Павлова Л.П. - МКУ «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» җитәкчесе;

Саттарова З.Ф. - Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең баш белгече;

Емельянов Ю.И. - Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы;

Чернов П.А. - муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе - Теләче муниципаль районы Олы Нырсы урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры.

6 номерлы кушымта
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«17» 03 2023 № 51
карары белән расланды

Муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, билгеләүне үзгәртү яисә юкка чыгару турында, балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешма тарафыннан аренда Шартнамәсе, ана беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану Шартнамәсе төзү, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура төзүче муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия составы

Комиссия рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Карпова Н.В. | - | МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» башлыгы. |

Комиссия секретаре:

| | | |
|---|---|---|
| Вахитова М.Г. | - | МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» башлыгы урынбасары. |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Трофимов Р.Ю. | - | Теләче муниципаль районы МКУ «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе»; |
| Емельянов Ю.И. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы; |
| Шәрипова Э.И. | - | Теләче муниципаль район Башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе; |
| Котдусов М.Х. | - | МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» юрист-консультанты; |
| Шәйхетдинов А.Р. | - | МБУ «Хуҗалык-эксплуатация конторасы» башлыгы. |